**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 22 маендагы 1783 номерлы карары**

**«Сабантуй» татар халык бәйрәмен әзерләү һәм уздыру чорында**
**Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап**
**юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү турында**

«Сабантуй» татар халык бәйрәмен әзерләү һәм уздыру максатыннан, шулай ук 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. кирәк булган очракта, әлеге карарның кушымтасы нигезендә «Сабантуй» татар халык бәйрәменә әзерлек һәм аны үткәрү чорында 2026 елның 19 июнендә 18.00 сәгатьтән 2026 елның 22 июнендә 08.00 сәгатькә кадәр Казан шәһәре автомобиль юллары буйлап юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртергә;

1.2 кирәк булган очракта, 2026 елның 19 июнендә 00.00 сәгатьтән 2026 елның 21 июнендә 23.59 сәгатькә кадәр «Казан» халыкара ат спорты комплексы янындагы парковка зонасының бөтен территориясендә, шул исәптән Альберт Камалиев проспектыннан Альберт Камалеев проспектындагы 27р номерлы йортка кадәр автомобиль юлы буйлап транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру схемасын эшләргә, аларны урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау чараларын оештырырга;

1.3.2. юл хәрәкәтен оештыруны вакытлыча үзгәртү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм MTC.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шәйнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләре (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) белән берлектә, кирәк булганда, юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябуны оештырырга;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карарның кушымтасы нигезендә Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;


2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) әлеге карарның кушымтасы нигезендә Казан шәһәренең автомобиль юллары буенча юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.


3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.


**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 22 маендагы
1783 номерлы карарына
кушымта

**Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары дислокациясе схемасы**




Оренбургский Тракт
Фермское Шоссе
Тульская
ТК «ПОРТ 2»
Братьев Батталовых
ТК «ПОРТ 1»
а/д на «Лесной городок»
Парковка
VIP парковка
Термена
а/д на сады
Площадь Сабантуй
(вход на майдан)
Ново-Давликеевская


ул.Горьковское Шоссе